2.3. Җирлекнең муниципаль хезмәткәрләренең дәрәҗәләр төркемнәре.

2.3.1. Җирлекнең муниципаль хезмәткәрләренә дәрәҗәләр төркемнәре бирелә һәм муниципаль хезмәткәрне профессиональ әзерлек дәрәҗәсе хезмәт вазифасын башкару өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.

2.3.2. Муниципаль хезмәткәрләренә түбәндәге дәрәҗәләр төркемнәре бирелә:

югары муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы – 1,2 яки 3нче дәрәҗәле хакыйкый муниципаль киңәшче;

баш муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль киңәшче;

әйдәп баручы муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт киңәшчесе;

өлкән муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт референты;

кече муниципаль хезмәт вазифаларын башкаручы - 1,2 яки 3нче дәрәҗәле муниципаль хезмәт сәркатибе.

Муниципаль хезмәт вазифаларын алда күрсәтелгән төркемнәргә кертү Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт Реестры белән туры китереп тормышка ашырыла.

2.3.3. Муниципаль хезмәткәрләргә дәрәҗәләр төркемнәре бирү тәртибе, һәм муниципаль хезмәткәрне башка муниципаль хезмәткә күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән алган очракта аларны саклау, Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәткәрнең хокук хәле

3.1. Җирлекнең муниципаль хезмәткәре.

3.1.1. Җирлекнең муниципаль хезмәткәре булып, федераль канunnar белән һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп, Җирлек муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә Җирлекнең муниципаль хезмәт вазифалары буенча вазифа башкаручы, Җирлек бюджетыннан түләнгән хезмәт хакы алып эшләүче гражданин тора.

3.1.2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең башка муниципаль оешмалары эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазифалар башкарган затлар Җирлекнең муниципаль хезмәте вазифаларын башкара алмый һәм муниципаль хезмәткәр булмый.

3.2. Җирлекнең муниципаль хезмәткәренең төп хокуклары.

3.2.1. Муниципаль хезмәткәр хокуклы:

1) муниципаль хезмәттә башкарган вазифалары буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, хезмәт вазифаларын башкару сыйфатын билгеләүче критерийлар һәм хезмәт буенча күтәрү шартлары белән танышуга;

2) хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәк булган оештыру-техник чараларны тәэмин итүгә;

